КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 786

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибен раслау турында» 2010 ел, 29 гыйнвар, 44 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибен раслау турында» 2010 ел, 29 гыйнвар, 44 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 28 май, 418 нче; 2010 ел, 6 сентябрь, 713 нче; 2011 ел, 4 март, 172 нче; 2011 ел, 31 октябрь, 895 нче; 2012 ел, 30 гыйнвар, 59 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1185 нче; 2018 ел, 27 гыйнвар, 47 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның «д» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

7 нче пунктта «3» санын «биш» сүзенә алыштырырга;

9 нчы пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бюджет кредиты бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

13 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин